ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Яруллина, д.7а, с.Малая Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422173

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яруллин ур., 7а йорт, Кече Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422173

тел.(факс): (85563) 3-07-03; e-mail: : Sun.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“22 ” декабря 2017 г. — № 11

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары белән расланган «Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 8 пункты, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Әлеге карарга кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеген расларга.

2. Эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында мәгълүматны урнаштыру түбәндәгечә башкарыла дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Югары Сон авылы, К.Маркс урамы, 10 йорт;

2. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Кече Сон авылы, Совет урамы, 22 йорт;

3. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Урта Сон авылы, Г.Тукай урамы, 28А йорт;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук кулланылган һәм яраксызга әйләнгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарында урнаштырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе /М.Ф.Сәләхов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге
башкарма комитетының
2017 елның 11 декабрендә
кабул ителгән 11 санлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге

| № | Терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары адресы |
|---|---|
| 1. | 422173, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Кече Сон авылы, Яруллин урамы, 7а йорт; (ярдәмче бүлмә). |